КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 гыйнвар г.Казань № 21

Азнакай муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетының Азнакай муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 6,2388 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчермәләрдә күрсәтелгән чикләрдә ритуаль эшчәнлек объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:02:100102:322 | 0,5861 |
| 16:02:100102:323 | 1,6954 |
| 16:02:100102:324 | 0,9023 |
| 16:02:100103:301 | 0,6030 |
| 16:02:100103:302 | 0,4826 |
| 16:02:100202:7 | 1,9694 |
| Барлыгы | 6,2388. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин